Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №LIV-9**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 5 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә вазифаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында”гы 2020 елның 7 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 4 апрелендәге XXVI-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 22.07.2013 ел № XXVII-6, 14.08.2014 ел №XXXIX-3, 13.12.2014 ел XLII-8, 14.11.2015 ел №V-3, 23.04.2016 ел №X-8, 16.11.2016 ел №XIII-9, 29.05.2017 ел №XIX-9, 23.10.2017 ел №XXII-6, 24.07.2018 ел №XXXII-4, 19.11.2018 ел № XXXVI-5, 20.12.2018 ел №XXXVII-2, 01.04.2019 ел №XLI-11, 22.07.2019 ел №XLIV-4, 24.09.2019 ел №XLV-13, 17.02.2020 ел № L-4 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 маддәнең 1 өлешендә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) әлеге Нигезләмәнең 7.1 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленең рөхсәтнамәсе белән түләүсез нигездә коммерциягә карамаган оешма (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан гайре) белән идарә итүдә катнашу;

в) муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда күздә тотылган башка очраклар;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктны өстәргә:

“3.1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 7.1 маддәне өстәргә:

"7.1 маддә. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы

1. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы (сәяси фирка, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан гайре) (алга таба әлеге маддәдә – коммерциягә карамаган оешма) әлеге маддәдә билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиленең рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр низагына яки мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3. Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә (әлеге маддәдә алга таба - гариза) түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү турында муниципаль хезмәткәрнең гаризасы, әлеге Нигезләмәнең 2.1 нче кушымтасында бирелгән рәвеш буенча аның нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең ялланган вәкиле исеменә язма рәвештә төзелә.

4. Гариза җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының (әлеге маддәдә алга таба – кадрлар хезмәте) кадрлар хезмәтенә (кадрлар эшен гамәлгә ашыру өчен җаваплы урындагы затка) коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган түләүсез нигездә катнашу башланганчы тапшырыла.

5. Гаризаны теркәү кадрлар хезмәте тарафыннан гаризаларны теркәү журналына кергән көнне гамәлгә ашырыла, ул әлеге Нигезләмәнең 2.2 нче кушымтасындагы рәвеш нигезендә алып барыла. Гаризаларны теркәү журналының битләре номерланган, кадрлар хезмәте яки җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

6. Теркәлү турында тамгалы гариза күчермәсе, гаризаны теркәү номеры, гаризаны теркәгән кадрлар хезмәте затының фамилиясен, инициалларын һәм вазифасын күрсәтеп, муниципаль хезмәткәргә аның гаризаларны теркәү журналында имзасын куйдырып бирелә.

7. Кадрлар хезмәте гаризаны һәм муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу мөмкинлеге йә мөмкинлеге булмау турында аңа дәлилле бәяләмә әзерләүне алдан карауны гамәлгә ашыра (алга таба –дәлилле бәяләмә (нәтиҗә)). Кадрлар хезмәте дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгәндә гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең (үзидарәлек хезмәткәренең) ризалыгын алып аның белән әңгәмә уздырырга һәм аннан язма рәвештә аңлатмалар алырга мөмкин.

8. Дәлилләнгән бәяләмәдә булырга тиеш:

1) коммерциягә карамаган оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник һәм башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү буенча муниципаль хезмәткәрнең вәкаләтләрен анализлау, шул исәптән әлеге коммерциягә карамаган оешма тарафыннан билгеле бер эшчәнлек төрен һәм (яки) аерым гамәлләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү белән бәйле карарларны;

2) муниципаль хезмәткәрдә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә аның катнашуы очрагында мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеген анализлау.

9. Гариза һәм дәлилләнгән бәяләмә гариза теркәлгәннән соң җиде эш көне эчендә яллаучы вәкиленә юллана.

10. Гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча яллаучы вәкиле түбәндәге карарларның берсен чыгара:

1) муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итәргә;

2) муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итмәскә;

3) гариза һәм дәлилләнгән бәяләмәне муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән комиссиягә муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеге булу яисә булмау предметына карауга җибәрергә.

11. Әлеге мадденең 10 өлешендәге 2 пунктында каралган карар кабул итү өчен нигез булып муниципаль хезмәткәрдә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеге тора.

12. Әлеге мадденең 10 өлешендәге 3 пунктында каралган очракта муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга

салу комиссиясе гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне аларны яллаучы вәкиле тарафыннан күрсәтелгән комиссиягә җибәрелгән көннән алып җиде көн эчендә карый. Гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр низагларын җайга салу комиссиясе муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашкан очракта мәнфәгатьләр низагы булу йә барлыкка килү мөмкинлеге булмау турында карар кабул итә.

13. Әлеге маддәнең 12 өлешендә каралган карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә яллаучы вәкиле муниципаль хезмәткәргә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашуны рөхсәт итәргә яисә рөхсәт итмәскә дигән карарны кабул итә.

14. Әлеге маддәнең 10 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында йә 13 өлешендә каралган карарларның берсен яллаучы вәкиле кабул иткән көннән алып өч эш көне эчендә кадрлар хезмәте муниципаль хезмәткәргә, гаризаларны теркәү журналында муниципаль хезмәткәрнең имзасын куйдырып, яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында язма рәвештә хәбәр итә яисә муниципаль хезмәткәргә яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында мәгълүматны почта элемтәсе аша тапшыру турында хәбәрнамә белән һәм бу хакта гаризаларны теркәү журналында билге куеп җибәрә.

15. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карап тикшерүгә бәйле башка материаллар (булганда) муниципаль хезмәткәрнең (үзидарәлек хезмәткәренең) шәхси эшенә куела.";

3) 19 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Дисциплинар җәзалар куллану һәм бетерү (алу) тәртибе, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.;

4) 19 маддәнең 4.9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.9. Әлеге Нигезләмәнең 8, 9 һәм 19.1 маддәләрендә каралган җәзалар, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, ялда булу чорларын санамыйча, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупцион хокук бозу кылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча производство вакыты кертелми.";

5) түбәндәге эчтәлекле 2.1 нче кушымта белән тулыландырырга:

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районында
муниципаль хезмәт турындагы
Нигезләмәгә кушымта 2.1

______________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрне

______________________________________________________

яллаучы вәкиле вазифасының

______________________________________________________

аталышы, инициаллары, фамилиясе )

______________________________________________

(муниципаль хезмәткәр

__________________________________________________

вазифасының аталышы,

__________________________________-нан, (-тан)

инициаллары, фамилиясе

коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү турында

ГАРИЗА.

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 1 өлеше 3 пунктының "б" пунктчасы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 маддәсе нигезендә миңа коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

_____________________________________________________________________________

(коммерциягә карамаган оешманың аталышы, аның урнашу урыны һәм адресы,

_____________________________________________________________________________

коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) нинди сыйфатта планлаштырыла, эшчәнлек төрләре)

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________.

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итү (идарә итүдә катнашу) хезмәттән буш вакытта гамәлгә ашырылачак һәм билгән муниципаль хезмәт вазифасы буенча вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү яисә мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеге килеп чыкмаячак.

_______________ ___________________________________ "___"___________20___ ел

(имза) (инициаллар, фамилия)

Гаризаларны теркәү журналында теркәү номеры

_______________________________________________

Гаризаны теркәү датасы "___"__________20__ел

___________________________________________________________

(имза) (гаризаны теркәгән зат вазифасының аталышы, инициаллары, фамилиясе )";

6) түбәндәге эчтәлекле 2.2 нче кушымта белән тулыландырырга:

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районында
муниципаль хезмәт турындагы
Нигезләмәгә  кушымта 2.2

Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә
катнашуга рөхсәт турында гаризаларны
теркәү журналы

| № п/п (гаризаның теркәү номеры) | Гаризаны теркәү датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза биргән затның инициаллары, фамилиясе, вазифасының аталышы | Гариза кабул иткән затның инициаллары, фамилиясе, вазифасының аталышы | Гаризаның күчермәсен алу турында билге ("күчермәсен алдым", гариза тапшырган затның имзасы) | Яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында билге | Гариза биргән зат тарафыннан яллаучы вәкиле карарының күчермәләрен алу турында билге ("күчермәсен алдым", гариза тапшырган затның имзасы) яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән яллаучы вәкиленең почта элемтәсе аша карарын юллау турында (карар җибәргән затның адресы, имзасы) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8". |

2. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Тажетдинов